ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.06.2022 № 722

«Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт
автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә
эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә
торган акчалата түләү бирү турында
нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 декабрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 7 пункты, 72 статьясындагы 2 өлеше, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча расларга:

2. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү буенча комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымтада каралганча расларга;

3. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү буенча комиссия составын 3 нче кушымтада каралганча расларга.

4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүне Алабуга муниципаль районы бюджеты турындагы карарга тиешле үзгәрешләр кертелгәннән соң

Алабуга муниципаль районы бюджетына өстәмә керем чыганаклары булганда, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары исәбенә бюджет ассигнованиеләрен кертүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 09 ” 06. 2022 ел
карарына 1 нче кушымта

«Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмә

1. 1. Әлеге нигезләмә «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибен һәм шартларын Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары чикләрендә шушы максатларга тиешле елда каралган акчалата ярдәм күрсәтүне билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү күләме һәр алучыга 500 000 (биш йөз мең) сум күләмендә билгеләнә.

Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучылар тарафыннан ипотека кредиты программасы буенча сатып алына торган яисә «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кысаларында сатып алына торган торак өчен түләү буенча бурычларны түләүгә яки ипотека кредиты шартнамәсе буенча беренче кертем кертүгә җибәрелә.

3. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан алдарак булмаган 1 (бер) ставкага «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белән хезмәт шартнамәсе төзегән табиблар бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъвачылар булып санала.

4. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъвачыларны сайлап алуның төп критерие булып «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе белән төзелгән хезмәт шартнамәсенең датасы һәм «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кысаларында сатып алына торган торак өчен түләү буенча яисә «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә хезмәт шартнамәсе төзелгән вакыттан кимендә алты ел дәвамында башкарылмаган шартнамә килешүе йөкләмәләре булу санала.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъвачыларның гаризаларын карап тикшерү эшен оештыру «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр акчалата түләүне бүлү комиссиясенә (алга таба - комиссия) йөкләнә.

6. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары әлеге нигезләмәне Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан расланган карар чыккан көннән башлап 10 эш көне эчендә «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга гаризалар җыя башлау турында әлеге нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән документларны җибәрү срогын һәм комиссия утырышының датасын (алга таба - хәбәрнамә) күздә тоткан белдерү кәгазе (алга таба-белдерү кәгазе) җибәрә.

7. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы хәбәрнамәдә билгеләнгән вакытта комиссия каравына түбәндәге документларны җибәрә:

1) табибның Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында гаризасы;

2) бер мәртәбә акчалата түләү алуга дәгъва кылучының шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

3) табиб һәм «Алабуга үзәк район хастаханәсе» автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе арасында төзелгән хезмәт шартнамәсенең күчермәсе;

4) Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кысаларында ипотека кредитлавы программасы буенча торак сатып алу турында шартнамә күчермәсе.

Документларның күчермәләре «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе кадрлар бүлеге тарафыннан таныкланырга тиеш.

8. Комиссия әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган документларны ун эш көне эчендә карап тикшерүне гамәлгә ашыра.

Комиссиянең бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү яисә бирүдән баш тарту турындагы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

9. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган документларны тапшырмау (тапшыру) (тулы күләмдә тапшырмау);

2) алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөреслеккә туры килмәү фактын билгеләү.

10. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алуга дәгъва кылучыларны сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат, табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне бүлү буенча комиссия утырышын үткәрү датасыннан алып, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты сайтында массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру юлы белән җәмәгатьчелеккә җиткерә.

11. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышын уздыру датасыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

12. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучылары күрсәтелгән, комиссиянең барлык әгъзалары да кул куйган беркетмә алынган көннән башлап 15 эш көне эчендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты грант бирү турында, бирелә торган грант күләме күрсәтелгән карар кабул ителә.

13. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә бер тапкыр акчалата түләү алучы арасында төзелгән шартнамә бер тапкыр акчалата түләү бирү өчен нигез булып тора. Шартнамә карар расланган көннән башлап, 20 эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә.

14. Акчаларны бер тапкыр акчалата түләү алучының банк счетына күчерү, килешү төзегәннән көннән башлап, 60 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

15. Әлеге нигезләмәнең 2 пунктында, комиссия секретаренда каралган әлеге түләүдән максатчан файдалануны раслый торган документлар (түләү йөкләмәләре, шартнамәләр), бер тапкыр акчалата түләү алучылар күрсәтелгән чараларны максатларга җибәргәннән соң 15 эш көне эчендә бирәлә. Комиссия секретаре әлеге пунктның беренче абзацында каралган бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алучы максатчан файдалану турындагы документларны карый һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә җиде эш көне эчендә җибәрә.

16. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белән«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе арасындагы үзара хезмәттәшлек өчен җаваплы Россия Федерациясе Бюджет кодексында кралган тәртиптә, бер

тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучыларның максатчан кулланылышын контрольдә тота.

Акчалардан максатчан файдаланмаган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле таләп куелганнан соң 10 эш көне эчендә район бюджетына кире кайтарыла.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 09 ” 06. 2022 ел
карарына 2 нче кушымта

**«Алабуга үзәк район хастаханәсе»**
**дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә**
**эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне**
**бирү буенча комиссия турында нигезләмә**

1. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү буенча комиссия (алга таба - комиссия) «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру кысаларында сатып алына торган торак өчен түләү буенча бурычларны түләүгә бер тапкыр акчалата түләүне бүлү турында объектив карар кабул итү максатларында төзелде.

2. «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү буенча комиссиясе «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәсенә таянып эш итә.

3. Комиссиянең оештыру структурасы һәм персональ составы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашу;

2) комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертү;

3) комиссия утырышында катнашу;

4) комиссия тарафыннан карауга чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашу;

5) карау өчен чыгарылган мәсьәлә буенча фикерне бәян итү.

5. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән, шулай ук түбәндәгеләрдән файдалана:

1) комиссия утырышларында рәислек итү һәм аның эшен оештыру;

2) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларга кул кую.

6. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук комиссия рәисе вазыйфаларын ул булмаганда башкара.

7. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән, шулай ук түбәндәгеләрдән файдалана:

1) комиссия эшен алып бару;

2) комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыру;

3) комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итү, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмати материаллар белән тәэмин итү;

4) комиссия утырышы беркетмәсен алып бару.

8. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда исемлек составындагы әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була.

Комиссия әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул карала торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

9. Комиссия карарлары тапшырылган документларны карау һәм аларны түләү кагыйдәләре таләпләренә туры килү-килмәү нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен комиссия әгъзаларының гомуми санынннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

10. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

11. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“09” 06. 2022 ел

карарына 3 нче кушымта

**«Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче табибларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү буенча комиссия составы**

| № п/п | Ф.И.А.и. | Вазифасы |
|---|---|---|
| 1 | Нургаянов Ленар Фәрид улы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе-комиссия рәисе |
| 2 | Яһудина Лилия Равил кызы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары-комиссия рәисе урынбасары |
| 3 | Рожкова Светлана Изаиловна | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кадрлар бүлеге башлыгы - комиссия секретаре (килешү буенча) |
| 4 | Садыкова Эльмира Илдар кызы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе (килешү буенча) |
| 5 | Сәфәров Рамил Рәфхать улы | Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы (килешү буенча) |
| 6 | Гайсин Азат Сөнәгать улы | Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча баш табиб урынбасары (килешү буенча) |
| 7 | Шалаумова Надежда Павловна | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы- |

| | | |
|---|---|---|
| | | комиссия әгъзасы |